# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар турында**

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын һәм урындагы затларын сайлаганда Татарстан Республикасында гражданнарның сайлау хокуклары гарантияләрен, җирле үзидарәнең халык тарафыннан турыдан-туры сайлана торган вәкиллекле органнары депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар тәртибен билгели.

2. Җирле үзидарәнең сайлап куелучы органнары, гражданнар җыены тарафыннан сайлана торган җирле үзидарә органнарын һәм урындагы затларын сайлаулар, шулай ук җирле үзидарә органнарын төзү тәртибе җирле үзидарә уставы белән җайга салына.

2 статья. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларның төп принциплары

1. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын (алга таба - депутатларын) һәм урындагы затларын сайлаулар гомуми, тигез, турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш биреп үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы гражданының сайлауларда катнашуы ирекле һәм ихтыярый була. Сайлауларда катнашуга яисә катнашмауга мәҗбүр итү максатында Татарстан Республикасы гражданына йогынты

ясарга, шулай ук аның ихтыярын ирекле белдерүенә каршылык күрсәтергә беркемнең дә хокукы юк.

3. 18 яше тулган һәм җирле үзидарә территориясендә яшәүче Татарстан Республикасы гражданы җирле үзидарә органнарына сайларга һәм сайланырга хокуклы.

4. Суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип табылган гражданнар, суд карары нигезендә ирегеннән мәхрүм итү урыннарында тотылучы затлар сайлана һәм сайлауларда катнаша алмыйлар.

3 статья. Сайлауларны билгеләү

1. Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар җирле үзидарәнең вәкиллекле органы тарафыннан җирле үзидарә уставында билгеләнгән вакытта, ләкин җирле үзидарә депутатларының һәм урындагы затларының вәкаләтләре чоры тәмамланырга 65 көннән дә соңга калмыйча, билгеләнә.

2. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органы күрсәтелгән вакытларда сайлауларны билгеләмәсә, сайлаулар җирле үзидарә вәкаләтле органының, депутатларының яисә урындагы затларының вәкаләтләре тәмамланган айдан соң килүче айның беренче яисә икенче якшәмбе көненә гражданнар җыены тарафыннан билгеләнә.

3. Сайлаулар көне билгеләнү турындагы карар ул кабул ителгән көннән 5 көннән дә соңга калмыйча матбугатта бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

4 статья. Сайлауларны финанслау

Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү җирле үзидарәләр бюджетлары акчалары исәбеннән финанслана.

## II бүлек. Сайлау округлары. Сайлау участоклары. Сайлаучылар исемлекләре

5 статья. Сайлау округлары төзү

1. Җирле үзидарә вәкиллекле органнарының депутатлары вәкиллекнең бердәм нормасы нигезендә җирле үзидарә территориясендә төзелгән бер мандатлы сайлау округлары яисә бер яки берничә күп мандатлы сайлау округлары буенча сайланалар. Күп мандатлы сайлау округларында мандатлар саны биштән арта алмый.

2. Депутатлар сайлауны уздыру өчен шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре тарафыннан, сайлау көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге таләпләрне саклап, сайлау округлары төзелә:

сайлаучылар саны буенча бер мандатлы сайлау округларының якынча тигезлеге, монда сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормадан 10 проценттан да күбрәккә тайпылуы рөхсәт ителми. Күп мандатлы сайлау округлары төзелгәндә депутат мандатына сайлаучылар санының якынча тигезлеге саклана;

сайлау округы бердәм территорияне тәшкил итә: сайлау округын бер-берсе белән чикләнмәгән территорияләрдән төзү рөхсәт ителми.

3. Җирле үзидарәнең урындагы затларын сайлаулар чикләре җирле үзидарә территорияләре чикләре белән тәңгәл килгән бердәм округ буенча уздырыла.

4. Сайлау округларының номерлары күрсәтелгән, чикләре тасвирланган һәм сайлаучылар саны күрсәтелгән исемлекләре алар төзелгәннән соң биш көн эчендә матбугатта бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6 статья. Сайлау участокларын төзү

1. Тавыш бирүне уздыру һәм сайлаучыларның тавышларын санау өчен сайлау участоклары төзелә.

2. Сайлау участоклары, сайлауларга кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, сайлау участогы территориясендә теркәлгән сайлаучылар саны турындагы күрсәткечләр нигезендә, һәр участокта 3000

сайлаучыдан да арттырмыйча, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре тарафыннан төзелә. Сайлау участокларының чикләре сайлау округлары чикләре белән кисешмәскә тиеш.

3. Сайлау участокларының номерлары, адреслары һәм сайлаучыларның саны күрсәтелгән, чикләре тасвирланган исемлекләре алар төзелгәннән соң биш көн эчендә матбугатта бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7 статья. Сайлаучылар исемлеге һәм аны төзү тәртибе

1. Сайлаучылар исемлеген сайлаучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан файдаланып алынган мәгълүматлар нигезендә участок сайлау комиссиясе төзи. Күрсәтелгән мәгълүматларны вәкаләтле орган яисә урындагы зат участок сайлау комиссияләренә җибәрә.

2. Сайлаучылар исемлегенә тавыш бирү көненә актив сайлау хокукына ия булган гражданнар кертелә. Сайлаучылар исемлегендә сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Сайлаучылар исемлеге алфавит тәртибендә яисә тавыш бирүне оештыру өчен уңайлы булган башка тәртиптә (торак пунктлары, урамнар, йортлар буенча) төзелә. Сайлаучы бүтән сайлау участокларының сайлау исемлегенә кертелә алмый. Сайлаучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә, аңа участок сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала, участок сайлау комиссиясе мөһере белән таныклана һәм, сайлауларга кадәр 20 көн кала, гомуми танышу өчен тәкъдим ителә.

3. Участок сайлау комиссиясе бинасында гражданнарга сайлаучылар исемлеге белән танышу һәм аны төзүнең дөреслеген тикшерү мөмкинлеге тәэмин ителә. Үзен исемлеккә кертмәүләре, дөрес кертмәүләре яисә исемлектән бөтенләй төшереп калдырулары турында, шулай ук сайлаучы хакындагы күрсәткечләрнең исемлектә төгәл күрсәтелмәве турында һәр граждан шикаять белдерергә хокуклы. Исемлектәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турындагы гариза участок сайлау комиссиясе тарафыннан карала, комиссия исә 24 сәгать

эчендә, сайлаулар көнне кичекмәстән гаризаны карарга, исемлеккә кирәкле төзәтмәләрне кертергә яисә гариза бирүчегә аның гаризасының дәлилле кире кагылуы хакында белешмә бирергә тиеш. Бу карар хакында югарыгы сайлау комиссиясенә йә судка шикаять белдерелергә мөмкин, алар исә шикаятьне өч көн эчендә, ә тавыш бирү көнне кичекмәстән карарга тиеш.

4. Тавыш бирү тәмамланып, сайлаучыларның тавышларын санау башланганнан соң сайлаучылар исемлегенә нинди дә булса үзгәрешләр кертү тыела.

8 статья. Сайлаучыларның өстәмә исемлеге

1. Сайлаучылар исемлеге халыкка җиткерелгәннән соң яңа яшәү урынына күчеп килгән яисә төрле сәбәпләр аркасында сайлаучыларның төп исемлегенә кертелмәгән сайлаучылар, аларның үтенече буенча һәм паспортларын яисә шәхес таныклыгын күрсәткәннән сон, аларның яңа яшәү урыны буенча сайлау участогындагы сайлаучыларның өстәмә исемлегенә кертеләләр.

2. Сайлаучыларның өстәмә исемлеге участок сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, аңа комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имза салына, ул участок сайлау комиссиясе мөһере белән таныклана.

III бүлек. Сайлау комиссияләре

9 статья. Сайлау комиссияләренең системасы һәм статусы

1. Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларны оештыру һәм үткәрү өчен түбәндәге сайлау комиссияләре төзелә:

шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе;

участок сайлау комиссияләре.

2. Сайлау комиссияләре үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан бәйсез булалар.

3. Сайлау комиссияләренең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән актлары җирле үзидарә органнары һәм урындагы затлары, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җәмәгать берләшмәләре, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

10 статья. Сайлау комиссияләрен төзү тәртибе

1. Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларны әзерләгәндә һәм үткәргәндә шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре төзелә. Күрсәтелгән комиссияләр җирле үзидарә уставы белән вәкаләтләр бирелгән орган яисә җирле үзидарәнең урындагы заты тарафыннан, ә алар булмаган очракта, сайлауларга 65 көннән дә соңга калмыйча, рәис һәм 6-8 әгъза составында гражданнар җыены тарафыннан төзелә.

2. Участок сайлау комиссиясе, сайлауларга 50 көннән дә соңга калмыйча, 5-7 әгъза составында шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә.

11 статья. Сайлау комиссияләренең вәкаләтләре

1. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе:

җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыралар, тиешле территориядә әлеге Законның үтәлешен тикшереп тора;

сайлау округлары төзи;

участок сайлау комиссияләре эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

сайлаучылар исемлекләрен төзүне һәм аларны гомуми танышу өчен бирүне күзәтеп тора;

җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына депутатлыкка һәм сайлап куела торган урыннарына кандидатлар күрсәтүне оештыра;

җирле үзидарә депутатлыгына һәм аның сайлап куела торган урынына кандидатларын, аларның ышанычлы затларын терки һәм аларга тиешле үрнәктәге таныклыклар бирә;

тавыш бирү өчен сайлау бюллетеньнәренең текстларын раслыйлар, аларны әзерләүне һәм участок сайлау комиссияләренә тапшыруны тәэмин итә;

җирле үзидарәнең бөтен территориясендәге сайлау округлары буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен ачыклыйлар, аларны матбугатта бастырып чыгара (халыкка җиткерә);

җирле үзидарәнең сайланган депутатларын һәм урындагы затларын теркиләр, аларга сайланулары хакында таныклыклар бирә;

участок сайлау комиссияләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турындагы гаризаларны һәм шикаятьләрне карый;

сайлау алды эшчәнлегендә барлык кандидатлар өчен бертигез хокукый шартларның үтәлешен тәэмин итә;

сайлаулар уздыру өчен үзләренә бүлеп бирелгән акчалар һәм матди чаралар белән эш итәләр, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына финанс хисабын тапшыра;

участок комиссияләренең биналар, транспорт, элемтә белән тәэмин ителешен тикшереп торалар һәм сайлауларны матди һәм техник тәэмин итүнең башка мәсьәләләрен карый;

кабат тавыш бирүгә һәм кабат сайлауларга бәйле мәсьәләләрне хәл итә;

җирле үзидарәнең киткән депутатлары һәм урындагы затлары урынына сайлауларны билгелиләр һәм аларны үткәрүне тәэмин итә;

җирле үзидарәнең депутатларын һәм урындагы затларын чакыртып алуга бәйле мәсьәләләрне гамәлдәге законнар нигезендә хәл итә;

сайлау документларын саклау тәртибен һәм вакытларын билгели;

әлеге Законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре яңа составтагы шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре төзелгәнчегә кадәр эш итәләр.

2. Участок сайлау комиссиясе:

сайлау участогы буенча сайлаучылар исемлеген төзи һәм аны гомуми танышу өчен тәкъдим итә;

сайлау исемлекләрендәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турындагы гаризаларны карауга ала һәм аларга тиешле үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләләрне хәл итә;

тавыш бирү бинасын һәм сайлау әрҗәләрен әзерләүне тәэмин итә;

участок сайлау комиссиясенең урнашкан урыны, аның эш вакыты, шулай ук тавыш бирү көне, вакыты һәм урыны турында сайлаучыларга хәбәр итә;

сайлау участогында сайлаулар көнендә тавыш бирүне оештыралар;

кандидатлар өчен бирелгән тавышларны саныйлар, сайлау участогында тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели;

сайлауларны әзерләү һәм тавыш бирүне оештыру мәсьәләләре буенча гаризаларны һәм шикаятьләрне карый, алар буенча карарлар кабул итә;

әлеге Закон нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Участок сайлау комиссияләренең вәкаләтләр чоры депутат яисә урындагы зат сайланганнан соң һәм сайлау документациясен югарырак сайлау комиссиясенә тапшырганнан соң тәмамлана.

<u>12 статья</u>. Сайлау комиссияләре әгъзаларының статусы

1. Сайлау комиссиясе составына депутатлар, дәүләт хакимияте органнарының һәм жирле үзидарә органнарының урындагы сайлап куелучы затлары, судьялар, кандидатлар, теркәлгән кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, кандидатларның, теркәлгән кандидатларның ире йә хатыны, якын туганнары яисә кандидатларның, теркәлгән кандидатларның турыдан-туры буйсынуындагы затлар керә алмыйлар.

2. Сайлау комиссиясе әгъзасы сайлау комиссиясенең барлык утырышларында катнашырга тиеш.

3. Сайлау комиссиясе әгъзасы:

тиешле сайлау комиссиясе утырышлары хакында алдан хәбәр ала;

сайлау комиссиясе утырышында чыгыш ясарга, тиешле сайлау комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм алар буенча тавыш бирү уздыруны таләп итәргә хокуклы;

сайлау комиссиясе утырышында башка катнашучыларга көн тәртибе нигезендә сораулар бирергә һәм аларга төпле җаваплар алырга хокуклы;

тиешле сайлау комиссияләренең машина чыганакларындагы документларын һәм материалларын да кертеп, теләсә кайсы документлар һәм материаллар (шул исәптән сайлаучылар исемлекләре, сайлау бюллетеньнәре) белән танышырга, аларның (сайлаучылар исемлекләреннән, сайлау бюллетеньнәреннән тыш) күчермәләрен алырга һәм бу күчермәләрне таныклауны таләп итәргә хокуклы;

сайлау комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата тиешле югарырак комиссиягә яисә судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләр чоры тәмамланганчы сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан үзен билгеләгән орган карары буенча түбәндәге очракларда азат ителергә мөмкин:

сайлау комиссиясе әгъзасының үз вәкаләтләрен туктатуы хакындагы язмача гаризасы булганда;

җирле үзидарә территориясеннән читкә даими яшәү урынына күчеп киткәндә;

сайлау комиссиясе әгъзасына карата судның хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә сайлау комиссиясе әгъзасы хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалану сәләте чикләнгән, кайдалыгы билгесез яисә вафат булган дип танылганда;

сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларын даими рәвештә үтәмәгәндә - сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча;

әлеге Законда каралган бүтән төрле нигезләр булганда.

5. Үз вәкаләтләре чорында сайлау комиссиясе әгъзасы администрация (эш бирүче) инициативасы белән эштән азат ителә алмый яки комиссия әгъзасының ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелә алмый.

6. Сайлаулар уздыру чорында сайлау комиссиясе әгъзасы район (шәһәр) прокуроры ризалыгыннан башка суд тәртибендә билгеләнә

торган җинаять җаваплылыгына яисә административ җәза гамәлләренә тартыла алмый.

13 статья. Сайлау комиссияләренең эшен оештыру

1. Сайлау комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре тиешле комиссиянең беренче утырышында сайлана.

2. Комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, сайлау комиссиясе утырышы тулы вәкаләтле була. Сайлау комиссиясе утырышлары рәис тарафыннан яисә аның кушуы буенча комиссия рәисе урынбасары тарафыннан чакырыла һәм үткәрелә. Утырыш шулай ук комиссия составының кимендә өчтән бере таләбе буенча да үткәрелә.

3. Сайлау комиссиясенең рәисен, рәис урынбасарын һәм секретарен сайлау турында, кандидатларны теркәү турында, кандидатларны теркәүне юкка чыгару турында, сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанс ягыннан тәэмин итү мәсьәләләре буенча, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү турында, сайлауларны үтмәгән яисә дөрес түгел дип тану турында, кабат тавыш бирүне үткәрү яисә сайлауларны кабат үткәрү турында сайлау комиссиясе карарлары тиешле сайлау комиссиясенең утырышында сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

4. Башка мәсьәләләр буенча сайлау комиссиясе карарлары сайлау комиссиясенең утырышта катнашучы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

5. Сайлау комиссияләренең карарларын кабул иткәндә «хуплап» һәм «каршы» бирелгән тавышларның саны тигез булган очракта, сайлау комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

6. Сайлау комиссиясенең карарларына сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала.

7. Сайлау комиссиясе кабул иткән карар белән килешмәгән участок сайлау комиссиясе әгъзалары үзләренең үзенчәлекле фикерләрен язма рәвештә белдерергә хокуклы, бу фикер өч көннән дә соңга калмыйча, ә сайлауларга өч көн кала һәм сайлау көнендә

кичекмәстән, югарырак сайлау комиссиясенә сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан җиткерелергә тиеш.

8. Участок сайлау комиссиясенең законны бозып кабул ителгән карары югарырак сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш.

9. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе участок сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата белдерелгән шикаятьләрне карый һәм биш көннән дә соңга калмыйча, ә тавыш бирү көнендә - кичекмәстән, төпле җавап бирергә тиеш.

14 статья. Сайлау комиссияләре эшчәнлегендә хәбәрдарлык

1. Сайлау комиссиясенең барлык утырышларында, шулай ук тавыш бирү көнендә сайлау комиссиясе сайлаучылар исемлеге белән, сайлау бюллетеньнәре, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр белән эш иткәндә югарырак сайлау комиссияләре әгъзалары, кандидат, теркәлгән кандидат яисә аның ышанычлы заты катнашырга хокуклы. Күрсәтелгән затларга өстәмә рөхсәт таләп ителми. Сайлау комиссиясе күрсәтелгән затларга утырышларда һәм күрсәтелгән сайлау документлары белән эш иткәндә хәбәрләшү һәм ирекле катнашу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. Утырышларда һәм күрсәтелгән сайлау документлары белән эш иткәндә шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

2. Тавыш бирү көнендә участок сайлау комиссиясенен эше башланган мизгелдән һәм шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә алыну турында хәбәр килгәнгә кадәр, шулай ук сайлаучылар тавышларын кабат санаганда күзәтүчеләр катнашырга хокуклы.

3. Күзәтүченең вәкаләтләре теркәлгән кандидат йә мәнфәгатьләре кайгыртылучы сайлаучылар тарафыннан язма рәвештә таныкланырга, аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, шулай ук сайлау участогының номеры, ул җибәрелә торган сайлау комиссиясенең исеме күрсәтелергә тиеш.

4. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуклы:

сайлаучылар исемлекләре белән танышырга;

тавыш бирү көнендә тиешле сайлау участогының тавыш бирү бинасында булырга;

сайлаучылар тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргәндә, шунда булырга;

сайлаучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның санын, сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәрен, тотылган сайлау бюллетеньнәрен санауны күзәтергә;

сайлау участогында сайлаучыларның тавышларын тавыш бирү бюллетеньнәренең эчтәлеген күрүне тәэмин итәрлек ераклыкта һәм шартларда саналуын күзәтергә;

сайлаучылар тавышларын санаганда тутырылган яисә тутырылмаган теләсә нинди сайлау бюллетене белән танышырга, сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәнең төзелүен һәм бүтән документларның тутырылуын күзәтергә;

тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссиясе беркетмәсе белән, шулай ук тиешле сайлау комиссиясенә кергән йә күрсәтелгән комиссия тарафыннан төзелгән бүтән документлар белән, шул исәптән тавыш биргәндә катнашкан затларның исемлеге белән дә танышырга. Күзәтүче таләбе буенча сайлау комиссиясе күрсәтелгән документларның расланган күчермәсен бирергә тиеш;

әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә участок сайлау комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка, ә шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата тиешле район (шәһәр) судына шикаять бирергә;

сайлаучылар тавышларын кабат санаганда, шунда булырга;

участок сайлау комиссиясе рәисенә, ә ул булмаганда аны алмаштыручы затка тавыш бирүне оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр, искәрмәләр белән мөрәҗәгать итәргә.

5. Күзәтүченең түбәндәгеләргә хокукы юк:

сайлаучыларга сайлау бюллетеньнәре бирергә;

сайлау бюллетеньнәре алганда сайлаучы үтенече буенча аның өчен имза салырга;

сайлаучы үтенече буенча сайлау бюллетеньнәрен тутырырга;

тавыш бирүнең яшеренлеген боза торган гамәлләр кылырга;

сайлау комиссиясе әгъзалары тарафыннан сайлау бюллетеньнәрен санау уздыруда турыдан-туры катнашырга;

сайлау комиссиясе эшенә комачаулый торган гамәлләр кылырга;

сайлаучылар арасында үгетләү алып барырга;

тиешле сайлау комиссиясе карарлар кабул иткәндә катнашырга.

15 статья. Сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү

Сайлау комиссияләренең җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар буенча карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Законда билгеләнгән тәртиптә район (шәһәр) судына шикаять белдерелергә мөмкин. Бу чакта югарырак сайлау комиссиясенә алдан мөрәҗәгать итү мәҗбүри шарт булып тормый.

## IV бүлек. Кандидатларны күрсәтү һәм теркәү

16 статья. Кандидатларны күрсәтү хокукы. Кандидатларны теркәү

1. Кандидатларны күрсәтү сайлауларга кадәр 60 көн кала башлана һәм 30 көннән дә соңга калмыйча тәмамлана.

2. Кандидатларны күрсәтүне тикшереп торуны тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тәэмин итә.

3. Кандидатлар тиешле сайлау округының сайлаучылары тарафыннан турыдан-туры һәм үзен үзе күрсәтү тәртибендә күрсәтелергә мөмкин. Затның кандидат булып чыгарга ризалыгы турында язмача гаризасы булганда, кандидат күрсәтелергә мөмкин, ул гаризада биографик характердагы белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, белеме, төп эш яисә хезмәт урыны (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда - шөгыльләренең төре), биләгән эш урыны, аның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүләре булганда, Россия Федерациясе Җинаять кодексының

кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре нигезендә кабул ителгән җинаять кодексы буенча, чит дәүләт законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары), гражданлыгы, шул исәптән чит ил гражданлыгы, аны алу датасы һәм нигезләре) күрсәтелә. Әлеге гариза, имзалар җыю башлану турындагы хәбәрнамә белән бергә, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенә җибәрелә. Кандидатның үзен үзе күрсәтүе шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенә кандидатларның язма гариза бирүе юлы белән, тулы биографик белешмәләрне күрсәткән һәм үзен хуплап имзаларны тагын җыю турында хәбәр иткән килеш гамәлгә ашырыла.

4. Бер мандатлы сайлау округы буенча күрсәтелгән кандидатны хуплар өчен округ сайлаучыларының кимендә 2 проценты күләмендә имзалар җыю таләп ителә. Күп мандатлы сайлау округы буенча кандидатны хуплау өчен сайлау округындагы сайлаучыларның мандатлар санына бүленгән санының кимендә 2 проценты күләмендә имзалар җыю таләп ителә.

Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлаганда теркәлгән сайлаучылар 10 мең кешедән ким булган территорияләрдә имзалар җыю үткәрелми.

5. Имзалар кәгазендә имза салган сайлаучы фамилиясен һәм инициалларын, туган көнен, адресын, паспортының яисә шәхесен таныклаучы башка документының сериясен һәм номерын күрсәтә. Имзалар кәгазе имзаларны җыйган зат тарафыннан таныклана, әлеге затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, адресы, паспортының яисә шәхесен таныклаучы башка документның сериясе һәм номеры күрсәтелә. Имзалар кәгазьләре әлеге Законга кушымтада күрсәтелгән рәвештә әзерләнә. Кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителгәнлеге булганда, имзалар кәгазендә Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең

гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре нигезендә кабул ителгән җинаять кодексы буенча, чит дәүләт законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Кандидатның чит ил гражданлыгы булса, имзалар кәгазендә тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш.

6. Сайлау комиссиясе әлеге статья нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү турындагы тәкъдим белән тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе кандидатны тәкъдим итүнең әлеге Законда билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә һәм 5 көн эчендә кандидатны терки, аның турындагы белешмәләрне бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә, аны теркәү турында таныклык бирә йә теркәүдән баш тарта.

7. Кандидатны теркәүдән баш тартуга карата район (шәһәр) судына шикаять белдерелергә мөмкин.

8. Җирле үзидарә органнарына һәм аның сайлап куела торган урыннарына кандидатларны теркәү сайлауларга 25 көн кала тәмамлана.

9. Кандидатны теркәү тавыш бирү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан түбәндәге очракларда юкка чыгарылырга (бетерелергә) мөмкин:

кандидатларны күрсәтү һәм теркәү кагыйдәләре бозылганда;

сайлау алды үгетләвен алып бару һәм сайлау кампаниясен финанслау кагыйдәләре бозылганда;

кандидатлар һәм аларның ышанычлы затлары тарафыннан сайлау максатларында вазыйфаи яисә хезмәт урыннарыннан файдаланганда;

кандидатларның сайлаучыларны сатып алу фактлары ачыклaнганда.

Шулай ук кандидат әлеге статьяда каралган белешмәләрне дөреслеккә асылда туры китереп бирмәгәндә дә, кандидатларны теркәү юкка чыгарылырга (бетерелергә) мөмкин.

17 статья. Теркәлгән кандидатларның эшчәнлеге гарантияләре

1. Барлык теркәлгән кандидатлар тигез хокукларга ия булалар һәм тигез бурычларны үтиләр.

2. Теркәлгән кандидат сайлауларны үткәрү вакытында администрация (эш бирүче) инициативасы буенча эшеннән азат ителми яисә үз ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелми.

3. Теркәлгән кандидат, район яисә шәһәр прокуроры ризалыгыннан башка, җинаять җаваплылыгына тартыла, кулга алына яисә суд тәртибендә бирелә торган административ җәза гамәлләренә тартыла алмый. Җинаять җаваплылыгына җәлеп итүгә, кулга алуга ризалык биргәндә, прокурор кандидатны теркәгән сайлау комиссиясенә бу хакта хәбәр итәргә тиеш.

4. Теркәлгән кандидат икедән күбрәк ышанычлы зат билгеләргә хокуксыз. Ышанычлы затларны теркәү кандидатның язма гаризасы нигезендә кичекмәстән шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Ышанычлы затлар теркәлгән кандидатны сайлауга ярдәм итәрлек үгетләүне һәм бүтән эшчәнлекне гамәлгә ашыралар. Ышанычлы затларны билгеләгән кандидатлар, бу хакта тиешле сайлау комиссиясенә хәбәр итеп, аларны чакыртып алырга хокуклы.

## V бүлек. Сайлау алды үгетләве

18 статья. Сайлау алды үгетләвендә катнашу хокукы

1. Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларны уздырганда теләсә кайсы теркәлгән кандидатларны хуплау яисә аларга каршы үгетләүне законнарда рөхсәт ителгән рәвешләрдә һәм законлы алымнар белән каршылыксыз үткәрү гарантияләнә.

2. Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайлау алды үгетләвендә катнашулары рөхсәт ителми.

19 статья. Сайлау алды гамәлләрен уздыру тәртибе

1. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары кандидатларга сайлау алды җыелышларын, сайлаучылар белән кандидатларның, аларның ышанычлы затларының очрашуларын оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм итәргә тиешләр.

2. Сайлау комиссиясе әгъзаларына сайлау алды үгетләвен үткәрү, теләсә нинди сайлау алды үгетләве материалларын тарату тыела.

3. Сайлаучыларга түләүсез яисә ташламалы шартларда товарлар сату, хезмәтләр күрсәтү (мәгълүмат хезмәтләреннән тыш), кыйммәтле кәгазьләр сату, шулай ук акча түләү юлы белән сайлау алды үгетләве алып бару тыела.

4. Үгетләү кампаниясе кандидатны теркәгән көннән алып барыла һәм тавыш бирү көненә бер тәүлек кала ноль сәгатьтә туктатыла.

VI бүлек. Сайлау бюллетеньнәре, тавыш бирүне оештыру һәм тавыш бирү тәртибе, сайлауларга йомгак ясау тәртибе

20 статья. Сайлау бюллетеньнәре

1. Сайлаулар өчен һәр сайлаучы билгеләнгән рәвештәге сайлау бюллетеньнәре ала. Сайлау бюллетеньнәре татар, рус һәм сайлау округына керүче халык файдалана торган телләрдә басыла. Сайлау бюллетеньнәре шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләренең карары нигезендә басыла. Сайлау бюллетеньнәренең саны теркәлгән сайлаучылар санының ике процентыннан да артыграк була алмый.

2. Сайлау бюллетеньнәренең рәвеше һәм тексты, бюллетеньнәрне әзерләү тәртибе, аларның саны, бюллетеньнәрне әзерләүгә карата куелучы таләпләр, тавыш бирү көненә 25 көннән дә соңга калмыйча, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре тарафыннан расланалар. Бюллетеньнәрнең тексты аның бер ягында гына урнаштырылырга тиеш.

3. Сайлау бюллетеньнәренә теләсә күпме кандидат кертелергә мөмкин.

4. Тавыш бирү өчен сайлау бюллетененә округ буенча теркәлгән барлык кандидатлар алфавит тәртибендә кертелә, анда аларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, шөгыленең төре һәм яшәү урыны, шулай ук аны күрсәтүчеләр турында мәгълүмат бирелә.

5. Уң якта һәр кандидат хакындагы белешмәләр турысына буш квадрат урнаштырыла. Кандидатлар исемлеге ахырында «Барлык кандидатларга каршы» дигән юл урнаштырыла һәм әлеге юлның да уң ягына буш квадрат куела.

6. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителгәнлеге булганда, сайлау бюллетенендә Россия Федерациясе Җинаять кодексы статьясының (статьяларынын) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларнын Җинаять законнары нигезләре нигезендә кабул ителгән җинаять кодексы буенча, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидатның чит ил гражданлыгы булса, сайлау бюллетенендә тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш.

7. Һәр сайлау бюллетенендә бюллетеньне тутыру тәртибе турында сайлаучыга күрсәтмә урнаштырылырга тиеш.

8. Сайлаулар көненә кадәр, әмма бюллетеньнәр әзерләнгәннән соң кандидатларнын кайберләре киткән очракта, тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссияләре күрсәтмәсе нигезендә участок сайлау комиссияләре сайлау бюллетеньнәрендә киткән кандидатлар турындагы белешмәләрне сызалар йә яңа бюллетеньнәр әзерлиләр.

<u>21 статья.</u> Тавыш бирү вакыты һәм урыны

Сайлаулар көнне тавыш бирү сәгать 7 дән 21 сәгатькә кадәр үткәрелә, җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар белән яисә референдум үткәрү белән туры килгәндә, шәһәр, поселок, авыл

сайлау комиссиясе тавыш бирү вакытын күчерү турында карар кабул итәргә хокуклы. Тавыш бирү вакыты һәм урыны турында участок сайлау комиссиясе, сайлауларга кадәр егерме көннән дә соңга калмыйча, сайлаучыларга хәбәр итә.

22 статья. Тавыш бирүне оештыру

1. Сайлаулар көнендә тавыш бирү махсус бүлеп бирелгән биналарда үткәрелә, аларда яшерен тавыш бирү өчен кабиналар җиһазландырылырга, сайлау бюллетеньнәрен бирү урыннары билгеләнергә һәм сайлау әрҗәләре куелырга тиеш.

2. Тавыш бирү бинасында йә турыдан-туры аның каршында участок сайлау комиссиясе стенд әзерли, анда барлык теркәлгән кандидатлар турында мәгълүмати материаллар урнаштыра. Теркәлгән кандидатның кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителгәнлеге булганда, мәгълүмати материалларда Россия Федерациясе Җинаять кодексының кандидатны хөкем итү өчен нигез булган статьясының (статьяларының) исеме (исемнәре) һәм номеры (номерлары), шулай ук, әгәр кандидат Россия Федерациясенең гамәлдәге Җинаять кодексы буенча җинаять дип танылган гамәлләре өчен ССР Союзы һәм союздаш республикаларның Җинаять законнары нигезләре буенча кабул ителгән җинаять кодексы буенча, чит ил законы буенча хөкем ителгән булса, әлеге закон актларының статьясы (статьялары) күрсәтелергә тиеш. Теркәлгән кандидат чит ил гражданлыгына ия булса, мәгълүмати материалларда тиешле чит дәүләтнең исеме күрсәтелергә тиеш. Стендта тутырылган сайлау бюллетеньнәренең үрнәкләре урнаштырыла, аларда теркәлгән кандидатларның фамилияләре булмаска тиеш. Мәгълүмати материалларда үгетләү рәвешендәге өндәмәләр булмаска тиеш.

3. Тавыш бирү бинасында сайлау бюллетеньнәрен бирү урыннары, тавыш бирү кабиналары һәм әрҗәләре сайлау комиссиясе әгъзаларының күз алдында булырга тиеш.

4. Сайлау әрҗәләре тавыш бирүчеләр алар янына килгәндә бары тик яшерен тавыш бирү кабинасы аша үтәрлек итеп урнаштырылалар.

5. Сайлау әрҗәләре участок сайлаулар көнне тавыш бирү алдыннан сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан сайлау комиссиясе әгъзалары катнашында тикшерелә, аларга пломба салына һәм мөһер сугыла. Шуннан соң гына сайлаучылар сайлау бюллетеньнәрен алырга чакырыла.

6. Һәр сайлаучы шәхсән тавыш бирә, башка кешеләр өчен тавыш бирү рөхсәт ителми. Сайлау бюллетеньнәре, сайлаучылар исемлеге нигезендә сайлаучы паспорт яисә шәхеснең башка таныклыгын күрсәткәннән соң, участок сайлау комиссияләре әгъзалары тарафыннан бирелә. Сайлау бюллетеньнәре алганда граждан сайлаучылар исемлегендә үз фамилиясе турысына имза сала.

7. Әгәр кайбер сайлаучылар сәламәтлекләре яисә башка мәгълүм сәбәпләр аркасында участок сайлау биналарына тавыш бирергә килә алмасалар, участок сайлау комиссиясе үзенең ике әгъзасына әлеге сайлаучылар торган урынга барып тавыш бирүне оештыруны йөкли. Бу максатлар өчен сайлау участогында барысы өч кечкенә күчерелмә сайлау әрҗәсе булырга тиеш.

8. Сайлаучылар гаризалары буенча йөрүче участок сайлау комиссиясе әгъзалары, кул куеп, язма яисә телдән бирелгән гаризалар санынча сайлау бюллетеньнәре алалар. Сайлау комиссиясе бөтен бирелгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне махсус реестрда терки. Телдән алынган мөрәҗәгатьне теркәгәндә, реестрда мөрәҗәгать итү вакыты күрсәтелә һәм әлеге хәбәрне алган комиссия әгъзасы имза сала. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларның фамилияләре аерым өстәмә исемлеккә кертелә, бюллетень алуын раслап, сайлаучы исемлеккә имза сала, ә участок сайлау комиссиясе әгъзасы аны бирүне раслап имза сала.

23 статья. Тавыш бирү тәртибе

1. Сайлау бюллетеньнәре сайлаучы тарафыннан яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган кабинада тутырыла, анда башка затларның рөхсәт ителми.

2. Сайлау бюллетенен алганда имза салырга һәм бюллетеньне мөстәкыйль тутырырлык мөмкинлеге булмаган сайлаучы моның өчен сайлау комиссиясе әгъзасы, теркәлгән кандидат, ышанычлы зат булмаган бүтән сайлаучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы.

3. Сайлау бюллетеньнәрендә сайлаучы үзе тавыш бирә торган кандидат (күп мандатлы округларда - кандидатлар) фамилиясе турысындагы буш квадратка (күп мандатлы округта - квадратларга) йә «Барлык кандидатларга каршы» дигән юл турысындагы квадратка теләсә нинди тамга сала. Тутырылган сайлау бюллетенен сайлаучы сайлау әрҗәсенә төшерә.

<u>24 статья.</u> Тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссиясе беркетмәсе

1. Участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) нөсхәнең номеры;

б) сайлауларның исеме, тавыш бирү датасы, сайлау участогының исеме һәм номеры;

в) «Беркетмә» сүзе;

г) сайлау участогының номерын күрсәтеп, сайлау комиссиясенең исеме;

д) беркетмә юллары:

1 юл. Сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре саны;

3 юл. Тотылган сайлау бюллетеньнәре саны;

4 юл. Тавыш бирү көнендә сайлау участогында сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

5 юл. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

6 юл. Күчерелмә тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

7 юл. Стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны;

8 юл. Гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәре саны;

9 юл. Гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәренең гомуми саны;

е) беркетмәгә кушымта итеп бирелүче шикаятьләр (гаризалар), актлар һәм башка документлар исемлеге;

ж) сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының, секретареның һәм башка әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары, аларның имзалары;

з) беркетмәгә имза салынган дата һәм вакыт (сәгатьләре һәм минутлары, әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса, беркетмәнең һәр бите саен);

и) сайлау комиссиясе мөһере (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса, беркетмәнең һәр бите саен).

2. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 10 юлына һәм аннан соңгы юлларына өстәмә рәвештә түбәндәгеләр кертелә:

сайлау бюллетененә кертелгән теркәлгән кандидатларның алфавит тәртибендә фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, ә алар бер-берсенә тәңгәл килгәндә - алар турында бүтән белешмәләр;

кандидатларның барысына да каршы сайлаучылар тарафыннан бирелгән тавышлар саны.

3. Әлеге статьяның 1-2 пунктларында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләргә цифрлап һәм язмача кертелә.

25 статья. Участок сайлау комиссиясендә тавышларны санау тәртибе

1. Тавыш бирү вакыты беткәч, участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирүнең тәмамлануы хакында игълан итә.

2. Тавышларны санарга керешкәнче, участок сайлау комиссиясе әгъзалары файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен саныйлар, юкка чыгаралар, аннары аларның санын игълан итәләр һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 3 юлына кертәләр.

Тотылган сайлау бюллетеньнәре санына тавыш биргәндә сайлаучылар тарафыннан бозылган сайлау бюллетеньнәре дә керә.

3. Шуннан соң участок сайлау комиссиясе әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы бит буенча түбәндәге суммар белешмәләрне кертәләр:

а) исемлеккә кертелгән сайлаучылар санын;

б) сайлаучыларга тавыш бирү көнендә бирелгән сайлау бюллетеньнәре санын (сайлаучыларның сайлаучылар исемлегендәге имзалары саны буенча билгеләнә);

в) сайлаучыларга тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).

4. Шушы белешмәләр кертелгәннән соң сайлаучылар исемлегенең һәр битенә участок сайлау комиссиясенең әгъзасы имза сала һәм бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, аннары бу күрсәткечләр сайлаучылар исемлеге буенча кушып тулысынча берләштерелә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертелә, участок сайлау комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының яки секретаренең имзалары һәм мөһере белән таныклана. Һәр бит һәм тулаем исемлек буенча йомгаклар игълан ителә.

5. Участок сайлау комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре түбәндәгеләрне аныклый һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 1 һәм 2 юлларына кертә:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын;

б) участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре санын.

6. Аннары беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

4 юлга - тавыш бирү көнендә сайлаучыларга сайлау участогында бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юлга - тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).

7. Бу гамәлләрдән соң участок сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре сайлаучылар исемлеген тавышларны санауда катнашучы затлар кагыла алмаслык итеп саклауны тәэмин итәргә тиешләр.

Сайлаучылар исемлеге белән алга таба эш итү, бары тик тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән белешмәләрнең контроль чагыштырмаларын тикшергәннән соң гына, әлеге статьяның 14 пункты нигезендә башкарылырга мөмкин.

8. Аннары участок сайлау комиссиясе әгъзалары тавыш бирү әрҗәләреннән алынган бюллетеньнәр буенча сайлаучылар тавышларын турыдан-туры санарга керешәләр.

Санарга керешкәнче, участок сайлау комиссиясе рәисе сайлау әрҗәләрендәге мөһерләрнең яисә пломбаларның бөтенлеген тикшерә һәм аларны ача.

9. Башта күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре санала. Аларның саны игълан ителә һәм беркетмәнең 6 юлына кертелә, ул тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турында сайлаучылар биргән гаризалар санынннан артмаска тиеш.

Күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге бюллетеньнәр санының күрсәтелгән гаризалар санынннан артып китүе ачыкланган очракта, күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге барлык сайлау бюллетеньнәре участок сайлау комиссиясе карары белән гамәлгә яраксыз дип таныла.

Бу факт, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне үткәргән участок комиссиясе әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары күрсәтелеп, аерым актта чагылдырыла, ул акт исә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә.

10. Аннары стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны санала һәм беркетмәнең 7 юлына кертелә.

11. Сайлаучыларның тавышларын санаганда, иң элек билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр, ягъни рәсми әзерләнмәгән йә сайлау комиссиясе тарафыннан таныкланмаган бюллетеньнәр исәпкә алына. Шулай ук гамәлгә яраксыз сайлау бюллетеньнәре дә аерып алына.

12. Сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерүләрен төгәл ачыклап булмый торган сайлау бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр дип санала, мондыйларга түбәндәгеләр керә:

бердән артык квадратка тамга куелган бюллетеньнәр (күп мандатлы округларда шушы округ буенча мандатларга караганда квадратлар күбрәк);

квадратларның берсенә дә тамга куелмаган бюллетеньнәр.

Шикләнүләр туган очракта, участок сайлау комиссиясе мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә. Бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип тану турында карар кабул иткәндә, сайлау комиссияләре аның арткы ягында гамәлгә яраксызлыгының сәбәпләрен күрсәтә. Бу язу участок комиссиясе рәисенең һәм секретареның имзалары белән таныклана. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр башка сайлау бюллетеньнәреннән аерым җыеп тутырыла. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны беркетмәнең 9 юлына язып куела.

13. Участок сайлау комиссиясе әгъзалары беркетмәнең 8 юлына гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәренең санын язып куялар.

14. Сайлау бюллетеньнәрен санаганнан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән белешмәләрнең контроль чагыштырмалары (2 нче кушымта) тикшерелә. Алар тәңгәл килмәгән очракта, участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык яисә аерым юлларын кабат санау турында карар кабул итә. Кабат санау нәтиҗәсендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә үзгәрешләр кертергә кирәк булса, беркетмәнең яңа бланкы тутырыла.

15. Санаганнан соң сайлау бюллетеньнәре аерым капларга тутырыла; «барлык кандидатларга каршы» тавышлары булган бюллетеньнәр - аерым, шулай ук гамәлгә яраксыз һәм юкка чыгарылган сайлау бюллетеньнәре дә аерым капларга тутырыла, һәр капта андагы сайлау бюллетеньнәренең саны күрсәтелә. Бер мандатлы сайлау округларында гамәлгә яраклы сайлау бюллетеньнәре сайлау бюллетенендәге һәр кандидат буенча аерым тутырыла. Шулай тупланган сайлау бюллетеньнәре капчыкларга яисә аерым тартмаларга салына, аларда сайлау участогының, округының үз номеры (исеме), сайлау бюллетеньнәренең саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга, пломба салып, мөһер сугыла һәм алар бары тик югарырак сайлау комиссиясе яисә суд карары белән генә ачылырга мөмкин.

16. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә өч нөсхәдә тутырыла һәм аларга участок сайлау комиссиясенең шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда имза салынган дата һәм вакыт (сәгате, минуты) язып куела.

17. Беркетмәнең эчтәлеге белән килешмәүче участок комиссиясе әгъзалары беркетмәгә үзләренең аерым фикерләрен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

18. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне карандаш белән тутыру һәм аңа нинди дә булса үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми.

19. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, тиешле законның бозылуына карата участок сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар), шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар кушып бирелә. Әлеге документларның таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә кушып бирелә.

20. Беркетмәнең беренче нөсхәсе кичекмәстән югарырак сайлау комиссиясенә җибәрелә.

21. Беркетмәнең икенче нөсхәсе, мөһерләнгән сайлау документлары белән бергә, сайлау бюллетеньнәрен һәм мөһерне дә кертеп, саклanучан бинада, мөһерләнгән килеш, участок комиссиясенең эше тәмамланганчы участок комиссиясе секретаренда саклана.

22. Беркетмәнең өченче нөсхәсе участок сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында гомуми танышу өчен эленеп куела.

26 статья. Сайлау округы буенча тавыш бирү йомгакларын эшкәртү

1. Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләренең беренче нөсхәләрендәге күрсәткечләре нигезендә шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе аларны төзүнең дөреслеген алдан тикшергәннән соң алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән округта тавыш бирү йомгакларын билгели.

2. Тавыш бирү йомгаклары буенча шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе беркетмә төзи, анда участок комиссияләре саны турында, участок комиссияләреннән алынган беркетмәләр саны турында белешмәләр кертелә, алар нигезендә тавыш бирү йомгаклары хакында беркетмә төзелә, шулай ук әлеге Законның 24 статьясында

билгеләнгән участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең аерым юлларындагы күрсәткечләр берләштерелә.

3. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе сайлау округы буенча сайлауларны түбәндәге очракларда узмаган дип таный:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның 35 процентыннан кимрәге сайлауларда катнашканда (сайлауларда катнашкан сайлаучыларның саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 4,5 юлларындагы саннарның суммасы белән билгеләнә);

б) бүтән кандидатка (кандидатларга) караганда иң күп тавыш җыйган кандидат өчен бирелгән сайлаучылар тавышларының саны барлык кандидатларга каршы бирелгән сайлаучылар тавышлары саныннан кимрәк булганда;

в) сайлау округы буенча бер генә кандидат теркәлеп, ул да кандидатлыктан төшеп калганда.

4. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе сайлау округы буенча сайлауларның нәтиҗәләрен түбәндәге очракларда гамәлгә яраксыз дип таный:

а) тавыш бирүне уздырганда яисә тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә әлеге Законны бозу сайлаучыларның үз ихтыярларын белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәгәндә;

б) сайлау участокларының кимендә дүрттән бер өлешендә алар гамәлгә яраксыз дип танылган очракта;

в) суд карары буенча.

5. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 50 проценттан күбрәк тавышын җыйган һәм теркәлгән кандидат бер мандатлы сайлау округы буенча сайланган дип таныла. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган һәм теркәлгән кандидатлар күп мандатлы сайлау округы буенча сайланган дип танылалар. Тавышлар тигез булганда, алданрак теркәлгән кандидатлар сайланган дип танылалар. Күп мандатлы сайлау округы буенча сайланган кандидатлар саны күп мандатлы округта сайланучы депутатларның билгеләнгән санына туры килергә тиеш.

Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның тавышлары саны тавыш бирү әрҗәләрендәге билгеләнгән рәвештәге сайлау бюллетеньнәре саны буенча билгеләнә.

6. Сайлау округында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм сайлау комиссиясенең шунда катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

7. Беренче нөсхәгә беркетмә төзегән сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук сайлау округының участок сайлау комиссияләренә кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлар кушымта итеп бирелә. Беркетмәнең беренче нөсхәсе шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясендә кала.

8. Беркетмәнең икенче нөсхәсе тиешле сайлау округында шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында танышу өчен эленеп куела.

27 статья. Сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү

1. Сайлау округларындагы тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрнең беренче нөсхәләрендәге күрсәткечләр нигезендә тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе, аларның дөрес төзелүен алдан тикшергәннән соң, тавыш биргәннән соң ике көннән дә соңга калмыйча, алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән сайлауларның нәтиҗәләрен билгели. Сайлау округларындагы тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушып берләштерүне шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенең әгъзалары үзләре башкаралар.

2. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе сайлау округында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр нигезендә сайлауларның нәтиҗәләре турында беркетмә төзи, аңа түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

а) тиешле территориядәге округлар саны;

б) сайлау округында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр саны, шуларга нигезләнеп әлеге беркетмә төзелә;

в) тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә булган барлык юллар буенча суммар күрсәткечләр.

Сайланган кандидатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелгән исемлек беркетмәгә кушымтада бирелә.

3. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсе ике нөсхәдә төзелә, аңа шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенең шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда аны төзү датасы һәм вакыты (сәгате һәм минуты) күрсәтелә һәм алар мөһер белән таныклана. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә түбәндәгеләр кушып бирелә:

а) сайлаулар нәтиҗәләре турында җыелма таблица, аңа тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссияләреннән алынган барлык беркетмәләрнең күрсәткечләре тулаем кертелә;

б) сайлау комиссияләренең сайлау бюллетеньнәрен алулары турында, шулай ук файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен (бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә) юкка чыгару турында актлар.

4. Җыелма таблицага һәм актларга шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе рәисе һәм секретаре имза салалар. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенең беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән әгъзасы беркетмәгә үзенең аерым фикерен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

5. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенең сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсенең беренче нөсхәсенә шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук әлеге Законның бозылуына карата шушы комиссиягә кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм әлеге шикаятьлар (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлар кушып бирелә.

6. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе, әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән җыелма таблицаның һәм актларның беренче нөсхәләре саклanучан бинада, мөһерләнгән килеш, комиссиянең вәкаләтләре тәмамланганга кадәр шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе секретаренда саклана.

7. Шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе беркетмәсенең икенче нөсхәсе шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында танышу өчен эленеп куела.

8. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага имза салынганнан соң һәм аларны югарырак сайлау комиссиясенә җибәргәннән соң беркетмәне, җыелма таблицаны төзегән

сайлау комиссиясе аларда төгәлсезлекләр (беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушып берләштергәндә төшеп калган, дөрес язылмаган очраклар йә хаталар) тапса, ул үзенең утырышында беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага төгәлләштерүләр кертү турындагы мәсьәләне карарга хокуклы. Кабул ителгән карар турында сайлау комиссиясе үз әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элегрәк расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә катгый рәвештә хәбәр итә. Бу очракта сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица төзи, аларда «Кабат» дигән тамга салына. Күрсәтелгән беркетмә кичекмәстән югарырак сайлау комиссиясенә җибәрелә.

9. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә хаталар, төгәлсезлекләр табылганда яисә түбәнгерәк сайлау комиссияләреннән килгән беркетмәләрнең дөрес төзелешенә шикләнүләр туган очракта, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тиешле сайлау округында (тиешле сайлау участогында) сайлаучыларның тавышларын кабат санауны уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

10. Тавыш бирү йомгаклары турында сайлау комиссиясе тарафыннан төзелгән һәм расланган беркетмә югарырак сайлау комиссиясе әгъзалары катнашында тикшерелергә тиеш. Сайлаучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча әлеге санауны гамәлгә ашырган сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән тамга салына. Әлеге беркетмә кичекмәстән югарырак сайлау комиссиясенә җибәрелә.

11. Сайлаулар йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салынганнан соң тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе бу хакта сайланган кандидатка хәбәр итә.

## 28 статья. Җирле үзидарәнең сайланган депутатларын һәм урындагы затларын теркәү

1. Тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе сайлау округларындагы тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләр нигезендә сайлауларга тулаем йомгак ясый һәм җирле үзидарәнең сайланган депутатларын һәм урындагы затларын терки.

2. Әгәр сайлаулар барышында яисә тавышларны санаганда йә округ буенча сайлауларның нәтиҗәләрен ачыклаганда шушы округ буенча сайлауларның барышына йогынты ясарлык итеп әлеге Законны бозу очраклары булса, сайлау комиссиясе теркәүдән баш тарта һәм сайлауларны дөрес түгел дип таный.

3. Теркәү турында бәхәсләр законда билгеләнгән вакытларда район (шәһәр) суды тарафыннан хәл ителә.

29 статья. Сайлауларның йомгакларын бастырып чыгару

1. Сайлауларның йомгаклары турындагы хәбәр, җирле үзидарәнең сайланган депутатларының һәм урындагы затларының исемлеге, сайлаулардан соң бишенче көннән дә соңга калмыйча, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан матбугатта бастырып чыгарыла (халыкка житкерелә).

2. Хәбәрдә сайлаучылар исемлегенә кертелгән гражданнарның гомуми саны һәм тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саны, шулай ук сайлаучыларның һәр кандидатны хуплап биргән тавышлары саны һәм «Барлык кандидатларга каршы» бирелгән тавышлар саны күрсәтелә.

3. Җирле үзидарәнең сайланган депутатларының һәм урындагы затларының исемлеге, аларның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, белгән эш урынын (шөгыленең төрен), эшләү һәм яшәү урынын, алар сайланган сайлау округларының номерларын күрсәткән килеш, алфавит тәртибендә бастырып чыгарыла.

## VII бүлек.
## Җирле үзидарә депутаты яисә урындагы заты булып сайлану турында таныклык. Сайлау документларының рәвешләре, аларны саклау тәртибе һәм чорлары

30 статья. Җирле үзидарә депутатының яисә урындагы затының таныклыгы һәм күкрәк билгесе

1. Җирле үзидарәнең сайланган депутатларын яисә урындагы затларын теркәгәннән соң шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе

аларга сайлану турында таныклык һәм тиешле күкрәк билгесе тапшыра.

2. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органына сайланган депутат яисә урындагы зат кире чакыртып алынганда яки судның гаепләү карары законлы көченә керүгә бәйле рәвештә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, таныклык һәм күкрәк билгесе тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенә кире кайтарылырга тиеш.

31 статья. Сайлау документларының рәвешләре

Сайлау бюллетеньнәренең, кандидатларны теркәү беркетмәләренең, кандидат һәм ышанычлы зат таныклыкларының, сайлау участогында тавыш биру йомгаклары турындагы беркетмәләрнең, округта сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәләрнең рәвешләре шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

32 статья. Сайлау документларын саклау тәртибе һәм чорлары

Сайлау документларын саклау тәртибе һәм чорлары шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

VIII бүлек.
Кабат тавыш бирү, кабат сайлаулар. Җирле үзидарә органнарына аның киткән депутатлары һәм урындагы затлары урынына сайлаулар. Җирле үзидарәнең яңа оешкан органнарына сайлаулар

33 статья. Кабат тавыш бирү

1. Әгәр бер мандатлы сайлау округы буенча икедән артык кандидат чыккан булса һәм аларның берсе дә сайланмаса, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе күбрәк тавыш җыйган ике кандидат буенча сайлау округында кабат тавыш бирү турында карар кабул итә.

Берничә кандидатның тавышлар саны тигез булганда, сайлау бюллетенендә алданрак теркәлгән ике кандидат кертелә.

2. Кабат тавыш бирү, әлеге Закон таләпләрен үтәгән килеш, ике атнадан да соңга калмыйча уздырыла. Кабат тавыш бирү турындагы хәбәр матбугатта басылып чыга (халыкка җиткерелә). Округта теркәлгән сайлаучыларның кимендә чиреге кабат тавыш бирүдә катнашса, кабат тавыш бирү узган дип санала.

3. Кабат тавыш биргәндә иң күп тавыш җыйган кандидат сайланган дип санала. Җыелган тавышлар тигез булган очракта алданрак теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

4. Бер генә кандидат өчен кабат тавыш биргәндә, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кимендә 50 процент тавышын җыйган кандидат сайланган дип санала.

34 статья. Кабат сайлаулар

1. Әгәр сайлау округы буенча ике генә кандидат чыккан һәм аларның берсе дә сайланмаган булса, йә сайлаулар уздырылмаган яисә дөрес түгел дип танылса, йә кабат тавыш бирү җирле үзидарәгә сайланган депутатны яки урындагы затны ачыклый алмаса, шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе бу округта кабат сайлаулар билгели. Бу очракта ул, әгәр кирәк булса, сайлауларны яңа составтагы сайлау комиссияләре тарафыннан уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин. Тавыш бирү шул ук сайлау участокларында һәм гомуми сайлаулар уздыру өчен төзелгән шул ук сайлаучылар исемлекләре буенча уздырыла. Кабат сайлаулар үткәргән очракта, әлеге сайлау округында гомуми сайлаулар барышында тиешле сандагы тавышларны җыя алмаган гражданнар депутатлыкка һәм сайлап куела торган урыннарга кандидат булып яңадан тавышка куела алмый, моңа сайлаулар дөрес түгел дип табылган округлар керми.

2. Кабат сайлаулар гомуми сайлаулардан соң ике айдан да соңга калмыйча уздырыла. Яңа сайлау комиссияләрен оештыру, әгәр моңа шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясенең карары булса, җирле

үзидарә депутатлыгына кандидатларны һәм урындагы затларны күрсәтү һәм теркәү, башка гамәлләр әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

3. Кабат сайлаулар уздыру һәм аларның нәтиҗәләре турындагы хәбәр матбугатта басыла (халыкка җиткерелә).

35 статья. Җирле үзидарәнең киткән депутатлары һәм урындагы затлары урынына яңаларын сайлауларны уздыру

1. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органына сайланган депутатны яисә аның урындагы затын чакыртып алганда, башка сәбәпләр аркасында аларның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, җирле үзидарәнең вәкиллекле органына сайланган депутат яисә урындагы зат киткәннән соң өч ай эчендә тиешле сайлау округларында өстәмә сайлаулар уздырыла.

2. Сайлаулар тиешле шәһәр, поселок, авыл сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм әлеге Закон таләпләрен үтәгән килеш оештырыла.

3. Җирле үзидарә депутаты яисә урындагы заты итеп сайланган зат җирле үзидарә вәкиллекле органының яисә урындагы затының вәкаләтләр чоры тәмамланырга 1 елдан да кимрәк вакыт калганда киткән очракта, аның урынына сайлаулар уздырылмый.

36 статья. Яңа оешкан җирле үзидарәләрдә җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларны уздыру

Яңа оешкан җирле үзидарәләрдә җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар җирле үзидарә оешкан көннән соң ике айдан да соңга калмыйча гражданнар җыены белән билгеләнә һәм әлеге Законда билгеләнгән вакытларда үткәрелә.

## IX бүлек. Йомгак нигезләмәләр

**37 статья.** Җирле үзидарә депутатларын һәм урындагы затларын сайлаулар турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

1. Татарстан Республикасы гражданының сайлау хокукын һәм җирле үзидарә депутаты яисә урындагы заты булып сайлану хокукын, сайлау алды үгетләве алып баруын ирекле рәвештә гамәлгә ашыруына көч куллану, алдау, янау яисә башка юллар белән каршылык күрсәтүче затлар, шулай ук сайлау комиссияләренең сайлау документларын үзләре теләгәнчә үзгәртүче, белә торып тавышларны дөрес санамаучы, тавыш бирүнен яшеренлеген бозучы яисә әлеге Законны башка төрле бозучы әгъзалары, дәүләт һәм җәмәгать органнарының урындагы затлары законда билгеләнгәнчә җаваплы булалар. Шулай ук кандидат турында белә торып ялган мәгълүматлар бастырып чыгарган яисә аларны башка ысуллар белән тараткан затлар да җаваплылыкка тартылалар.

2. Кандидат әлеге Законны бозган очракта, аңа үзен теркәгән сайлау комиссиясе кисәтү ясый, ә кабат бозганда, кандидатны теркәү турындагы карарны юкка чыгарырга мөмкин, бу хакта тиешле сайлау округы халкына хәбәр ителә.

3. Сайлауларга әзерләнү чорында яисә сайлаулардан сон сайлаулар турындагы законнарны бозу хакында сайлау комиссияләренә, дәүләт һәм җәмәгать органнарына килгән гаризалар биш көн эчендә каралырга, ә сайлауларга бер көн кала яисә сайлаулар көнне килгәннәре - кичекмәстән каралырга тиеш.

38 статья. Норматив хокукый актларны әлеге Законга яраклаштыру

Җирле үзидарә органнарына үзләренең норматив хокукый актларын әлеге Закон үз көченә кергәннән соң 6 ай эчендә аңа яраклаштырырга тәкъдим итәргә.

39 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законны кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең вакытлыча үрнәк уставы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 1995 елның 25 гыйнварендагы 2315-XII номерлы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1995 ел, № 1) белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең вакытлыча үрнәк уставының VII бүлеге үз көчен югалта дип танырга, моңа әлеге статьяның 3,4 пунктларында күрсәтелгән очраклар керми.

3. Әлеге Закон ул үз көченә кергәнче билгеләнгән сайлауларны уздырганда кулланылмый.

4. Кабат сайлаулар, шулай ук җирле үзидарәнең киткән депутатлары һәм урындагы затлары урынына сайлаулар уздырганда төп сайлауларны әзерләгән һәм уздырган вакытта гамәлдә булган нормалар кулланыла.

5. Җирле үзидарәнең ыәкиллекле органнары депутатларын һәм урындагы затларын сайлауларда тавыш бирү көнен Россия Федерациясе Президентын сайлауларында тавыш бирү көне белән туры китерү максатларында 2000 елда вәкаләтләре беткән җирле үзидарә органнарының һәм урындагы затларының вәкаләтләре чорын озайту яисә кыскарту рөхсәт ителә.

6. Әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән очракта, шулай ук җирле үзидарә органнарының һәм урындагы затларының 2000 елның 1 маена кадәр вәкаләтләре чоры беткән очракта, сайлау гамәлләренең вакытларын пропорциональ кыскарту рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 21 гыйнваре
№ 36